**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**Совет города Арск**
**422000,г. Арск, площадь Советская , 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Арча шәһәр Советы**
**карары**

**22 ноябрь 2018 ел** **№_107_**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советының 2016 елның 22 гыйнварындагы 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турындагы Нигезләмәдә.

1) 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1 Үзара салым акчаларын җыю тәртибе башкарма комитет карары белән билгеләнә».

2) 5.2-5.4 пунктларын үз көчләрен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт; Арча шәһәре, Совет мәйданы, 25 йорт; Арча шәһәре, Х. Такташ урамы, 58 йорт, Арча шәһәре, Өрәңге урамы, 4 йорт; Арча шәһәре, Банк урамы, 2А йорты.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

“Арча шәһәре” муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г.Нуриев